Хәерле көн хөрмәтле авылдашлар,
авыл җирлеге депутатлары, килгән кунаклар!

Азнакай районы Сәпәй авыл жирлегенә 2 авыл керэ: Сәпәй һәм Мачаклы Баш.

Барлыгы 317 хуҗалыкта 711 кеше яши. Сәпәйдә 265 хуҗалыкта 649 кеше, Мачаклы- Башта 52 хуҗалыкта 62 кеше. Эш яшендәгеләр- 431, эшләүчеләр-441, мәктәпкәчә яшьтәгеләр-52, мәктәп яшендә-82, студентлар-7, пенсионерлар 160 кеше.

2021 елда җирлектә 6 бала туды, 12 кеше улде. Туучылар саны 2020 елга караганда 1 гә, үлүчеләр саны 3 кә кимерәк.

Җирлектә 2022 елнын беренче январенә 98 (2021-117) баш могезле эре терлек бар, шуларнын 34 (2021-44) сыер малы, кәҗә-сарык малы 83 баш, атлар 12 баш, куяннар 43 баш һәм 41 баш умарта бар.

4 сыер тотучы- 3 хуҗалык (Григорьев Сергей, Нуркаев Ильнур, Хабибуллин Равиль);

2 сыер тотучылар-2 хуҗалык (Харисов Халиль, Шубина Гульчира)

2021 елда савым сыерларга һәм савым кәҗәләргә бирелә торган субсидия 2020 елдагыча түләнде. 1 савым сыеры булганнарга-2300 әр сум, 2 савым сыеры булганнарга-3300(1сыерга); 3 һәм аннан кубрәк сыер булганнарга һәр сыерга 4300сум. 300 сумы -кан алдырганда тулэгэн 500 сумга субсидия.

Савым кәҗәләргә субсидия куләме -500 сум. Әлеге мал ияләренен исемлекләре тозелеп, кирәкле документларын туплап, авыл хуҗалыгы идарәсенә илтеп тапшырылганнан сон, мал хуҗаларының банк счетларына 102 000 сум куләмендә субсидия кучте. **Шуны искәртеп үтәргә кирәк, субсидия алу очен, мал башының 1 январьгә хуҗалык китабында теркәлгән булуы шарт.**

**Хәрби комиссариат** эшенә килгәндә, 3 егетебез – Харисов Ильназ Халил улы, Хусаенов Ильназ Ришат улы, Заляев Ролан Роман улы армия хезмәтеннән әйләнеп кайттылар, ә бер егетебез- Галиуллин Айзат Айрат улы хезмәт итәргә китте. Исән-сау йореп кайтсын дигән теләктә торабыз. Запаста 111 кеше теркәлгән. Көзге чакырылышта комиссиягә 4 кеше барырга тиеш булып, шуларнын 4 дә комиссия утте.

**Паспорт-виза хезмәте**

Ел дәвамында җирлектә 49 кеше теркәлде (шунын 6 сы- яна туган балалар), 32 кеше исәптән тошерелде (шунын 12 е-үлүчеләр).

**Нотариус хезмәтен** башкаруда узгәрешләр керде. 2019 елдан авыл җирлеге кучемсез милек белән идарә иту (сату, алу, бүләк итү) очен ышаныч кәгазе-доверенность, васыятнамә-завещание раслый алмый. Мондый төр хезмәтләрне бары тик Азнакай шәһәрендә урнашкан нотариуслардан гына алып була.

Узган елда 5 ышанычнамә язылып, 1860 куләмендә дәуләт пошлинасы керде.

**Җир һәм мөлкәтне рәсмиләштерү** буенча мөлкәтләрен рәсмиләштермәүчеләр барланды. Барлыгы 8 җир, 5 йорт рәсмиләштерелмәгән.җир участогы җирлек биләмәләренә кермәгән булу сәбәпле, 1 хуҗалык (Тукай 31) җирен терки алмыйча йори. Шул участокны кертеп, тагын 43 гектар участокны кертеп, җирлек чикләре киңәйтелде. Киңәйтелгән җирләрне генерал планга керту очен, "Татинвестграждан проект оешмасы белән килешу тозелде.

Җирлектә **салым җыю** һәр елны оешкан төстә бара. Салым квитанцияләрен авыл почта булеге өйләргә тарата һәм тулэуләрне кабул итэ. Телэгэн кешеләр интернет челтәрендә "Госуслуги", "Налог ру" порталы аша да салымын узләре түләде. Шулай булуга да карамастан, елнын елында кайбер кешеләр туләмичә кала. Кабат-кабат шалтыратып, өйләренә барып йорергә туры килә. Тулэнмэгэн налоглар, әҗәтләре (пеня) булган кешеләрне вакытында салымнарын туләргә өндәр идем. ***Чонки, салым оешмасына әҗәтләре булган кешеләргә социаль яклау идарәсеннән алына торган һәм савым сыер, кәҗәләр очен бирелә торган субсидияләр тулэнмиячәк.***

**Җирлек Советында Бердәм Россия партиясеннән 7 депутат сайланып, уңышлы гына эшләп киләләр. Агымдагы елда депутатлар утырышында** 30 дан артык карар кабул ителде. Һәрдаим депутатлар белән курешеп халыкнын мөрәҗәгатләрен, узара салымны нинди төр эшләргә тоту турында, тотылган акчаларга нәтиҗә ясау буенча киңәшуләр уздырылып торыла. Ел дәвамында район башлыгына 6, авыл җирлеге башлыгы һәм район Советы депутатына 16 **гражданнар мөрәҗәгате** теркәлеп каралды. Шуларнын язмача теркәлгәне-3, телдән бирелгән сораулар -16. Купчелек сораулар урам яктырткычларын алыштыру, хуҗасыз йөргән этләр, җир һәм мөлкәтне рәсмиләштеру буенча туган сораулар.

2021 елнын 17-19 сентябрьдә Рәсәй дәүләт Думасына сигезенче чакырылыш депутатлар **сайлавы** узды. Сайлауларда Республика һәм районыбыз житәкчелегенә ышанычыбызны моңа чаклы да күрсәтелгән активлык белән катнашып расладык. Битараф калмыйча сайлауларга килгән авылдашларга, участок сайлау комиссиясенә рәхмәтемне белдерәм.

**Җирлектә эшләнелгән программалар:**

Сәпәй авыл җирлеге 2021 елда Сәпәй авылында урам яктырткычларын заманча светодиод яктырткычларга алыштыру буенча Республика программасына керде. 91яктырткыч алыштырылды һәм 8 яктырткыч остәмә урнаштырылады.

Элеккеге балалар бакчасы территориясендә алдагы елларда балалар өчен уен һәм спорт мәйданчыклары урнаштырылган иде. Шул территорияне тозекләндеру максатыннан кече футбол мәйданы ясарга, яңа капка куярга, капкадан кергән олешенә матурлап коляскалар, балаларга велосипед белән йөрерлек итеп юл салырга дип программага керер өчен проект-смета ясап Авыл хуҗалыгы министрлыгына тапшырылган иде. Республиканын "Авыл жирлеклэрен төзекләндерү программасы"на кереп (1 145 000 сум) балалар очен

футбол мэйданчыгы тозелде, яна капкалар куелды, тротуар плиткасы тушэлеп, эйлэнэ тирэсенэ тэртип урнаштырылды.

2012 елда жирлектэ Федераль программа нигезендэ районнын куп балалы гаилэлэренэ жир кишэрлеклэре булеп бирелгэн иде. 10 нан артык гаилэ йорт тозеп, яшэргэ килучелэр бар. Яна урамда 8 йортта хэм яна микрорайонда газ уткэрелмэгэн иде. 2021 елда проект ясалып 1111 номерлы 22.11 2021 елгы Татарстан республикасы министрлар кабинеты постановлениесе нигезендэ газ трубалары уткэру очен программага кердек. Жирлектэн йорт-жирлэре тиешенчэ теркэлгэн 15 гаилэ гариза язып, бугенге кондэ 3нче гаилэгэ газ уткэру эшлэре бара. Бу эшлэр ел азагына чаклы дэвам итэчэк. Кызыксынган кешелэр Азнакай газ участогына йорт-жир документлары белэн барып гариза калдыра алалар.

2022 ел башы белэн алда эйтеп утелгэн куп балалылар очен бирелгэн жирлэр микрорайонына су уткэру буенча проет документлары эзерлэу остендэ эш алып барыла. Проектыбыз хуплау тапса, су уткэру буенча Республика программасына керу турында эш барачак.

Мэдэният йортыбызга куптэн ремонт кирэклеген район житэкчелэренэ житкереп, программага керу очен документлар тутырган идек. Нихаять, 2021 елда олешчэ ремонтка акча буленде. Электр чыбыклары, розеткалар, сэхнэ ягында олешчэ яраксызга эйлэнгэн жылылык трубалары алыштырылды, фоеда тушэм аыштырылды, янгын куркынычсызлыгы коесын хэм линиялэрен тиешле стандартка туры китереп эшлэнелде хэм юыну-санитар булмэсе булдырылды. Кайнар су хэм канализация чокыры ясалып, клуб хезмэткэрлэренен эшлэре купкэ жинелэйде.

Барлык эшлэгэн эшлэр, авылыбызга ярдэм очен президентыбыз Ростэм Нургалиевичка, районыбыз башлыгы Марсель Зуфаровичка, анын командасына зур рэхмэтебезне житкерэбез.

Һәр елдагыча апрель аенда **<u>санитар-экологик ике айлык</u>** игълан ителә. Кар эри башлау белән өмәләр оештырыла. Тымытык юлыннан Сухояшка борыла торган юл чатына, Яшьләү юлыннан Мачаклы Баш авылына чаклы ике яклап юл буйлары, авыл эчендәге урамнар, купер төпләре, һәйкәл, зират буйлары җыештырылды. Бюджет оешмалары хезмәткәрләре, авыл халкы да бик актив рәвештә ярдәм итә. Сәпәй, Мачаклы Баш авыллары, Зирекле Елга зиратларында- (барлыгы 5 зират) авыл халкы һәм читтән кайткан авылдашларыбыз көче белән өмәләр уткәрелде. Мачаклы Башта бу эшләрне башлап йорүче хөрмәтле Флера апа Яхиевнага, уз көчләре, техника белән ярдәм иткән авылдашларга аерым рәхмәтне җиткерәсе килә.

Җәй айларында юл буйларын, купер төпләрен, зират буйларын чуп уләннәреннән арындырып тоту максатыннан, килешу нигезендә 2 кеше эшкә алынды. Кечкенә трактор, триммер белән бу эшләр җәй дәвамында башкарылды.

Кыш коне 2 авылда да юлларны кардан даими чистартып торырга кирэк. Бу эшлэргэ Автомобиль Юллары идарэсе ризалашмый. Алдагы елларда, моның өчен шәхси эшмәкәр Раил Усманов белән килешу төзелгән иде. Эмма, 2021 елда бу эшмэкэр ризалашмады. Авырлык белэн, болай да 4 авыл жирлеге белэн эшлэп килуче эшмэкэр Агелетдинов Даниль белэн бик озак сойлэшулэрдэн сон, килешу тозедек. Кар явып үткәч, юлларны тиз арада чистартып куярга кирэк. Эшлэре

тыгыз булу сэбэпле агымдагы елда бу эшлэр без телэгэнчэ бик бармый. Шулай да, егетлэр тырышалар, тонлэ булса да килеп эшлилэр, зур рэхмэт аларга.

Хөрмәтле авылдашлар! Белгәнегезчә 2014 елдан **узара салым жыю программасы** эшли. 2021 елда да бу программа дәвам итте. Халыктан жыелган 176 050 сумга Республикадан 704 200 сум кучерергә тиеш булып, салым акчасын тиешле вакытында жыеп алынганлыктан бу акча тулаемы белән счетка утырды. Акча жыю бик авырлык белән барды, кабат-кабат өйләргә йормичә күп кенә авылдашлар тиешле салымны түләмиләр.

Бу акчаларга жирлектә куп кенә яңарту эшләре, җәйге-кышкы сезон эшләре, куп кенә чаралар уткәрелде. Эшләнгән эшләр буенча еллык нәтиҗә ел саен ноябрь аенда уткәрелгән халык жыенында да бөртеклэп анлатыла. Алдагы елга максатлар- әйтеп уткәнемчә депутатлар корпусы белән киңәшеп халыкнын үтенечен исәпкә алып билгеләнә.

**2021 елга салым акчасына түбәндәге эшләр эшләнде**:

- Сәпәй авыл зиратларына контейнер мәйданчыклары урнаштыру- *Прокуратура таләбе:*2 зиратка 126 114,31сум **(25 222,86+100 891,45)**
- Авыл урамнарына юлларга(чокырларга) вак таш ташып жәю- 290 250,00.(**58 050+232 200**) (Яна урам, Мэктэп, Хасаншиной урамнары)
- Урам утлары челтәрен төзекләндерү-60 000**(12000+48000)**
- 2 авыл территорясен-урамнарны, юл буйларын, зиратларны, күпер яннарын чүп үләннәреннән чистартып, чабып тору-120 000 (**24000+96 000**);
- 2 авылнын урамнарын даими кардан чистартып тору-100 000;(**20000+80000**)
- Авыл территориясен көндәлек чүптән жыештыру- 70 000 (**14 000+56000**);
- Жирлектәге бәйрәм чараларын уткәру: Жиңу бәйрәме, Сабантуй, өлкәннәр көне һәм яңа ел бәйрәме-100 000 (**20000+80000**).

Бәйрәм чаралары 2021 елда бераз экономия белән утте. Карантин чикләуләре белән милли Сабантуй бәйрәме башка еллардагыга караганда жыйнагырак булды. Җиңу бәйрәме дә өлкәннәребезне чакырмыйча, ветераннар советы рәисе, авыл активы белән искә алынып, һәйкәлебезгә чәчәкләр куелды. Өлкәннәр айлыгында, һава торышы яхшы булганлыктан, бәйрәмне урамда уткэрдек. Шуна курэ, бу тор эшкэ каралган узара салым акчасы экономия белән тотылып, калган олеше (47000) 2022 елга кучерелде.

Узара салымны жыюны 2022 елда да дәвам итэбез. Бу эшкә бераз яналык кергәнен беләсез. 2019 елдан һәрбер авылдан җыелган акча үз авылы эшләре өчен генә тотыла. **Вакытында тулэп, безнен белэн бергэ шул эшлэрне эшлэгэн, кинэшлэре белэн ярдэм иткэн авылдашларга рэхмэт эйтеп кул чабыйк эле.**

**2022 елга планга кертелгэн эш торлэре:**

- 2 авылның урамнарын даими кардан чистартып тору-174 375 **(34875+139500)**;
- 2 авылның урам утлары челтәрен төзекләндерү-80 000 **(16 000+64000)**;

- Сәпәй авылы зират буйларын, зират эчләрен чүп үләннәреннән чистарту, агачларны кисеп. куаклардан арындыру, чуплэрен жыеп чыгару- 201 375,00 **(40 275+161 100);**
- 2 авылның территорясен-урамнарны, күпер яннарын, юл буйларын чүп үләннәреннән чистартып, чабып тору- 143 885,69 (**26 000+104000+ 13885,69-2021год**);
- Жирлек, Башкарма комитет ихтыяҗлары өчен генератор сатып алу-75 000 **(15 000+60000);**
- Жирлектәге бәйрәм чараларын уткәру: Жиңу бәйрәме, Сабантуй, өлкәннәр көне һәм Яңа ел бәйрәме-125 000 **(25 000+100 000).**

Хөрмәтле авылдашлар! Авыл очен, барыбыз очен дә бу чаралар кирәкле дип уйлыйм. 1 мартка кадәр узара салым акчаларын тапшырып бетерелергә тиеш булып, бугенге көндә **50 %** кына җыелды. Акчаларны счетка салып Финанс Министрлыгы акчаны кургәч кенә өстәп түләү буенча карар кабул ителә. Республика безгә дигән акчаны кучереп, Республика акчасы безнен счетта куренмичә материал өчен, планлаштырган эшләр өчен акчаларны тотып булмый. Шул авылда яшәп, утлар, сулар, юллар белән кулланып тиешле салымны туләми калу бердә килешә торган эш тугел хөрмәтле авылдашлар.

**Бюджет оешмалары эшенен торышы**

Җирлектә «Кояшкай» балалар бакчасы, Фельдшер Акушерлык Пункты, мәдәният йорты, библиотека, почта, 2 магазин һәм авыл мәчете эшләп килә.

**«Кояшкай» балалар** бакчасында бугенге кондэ 12 бала йорергэ тиеш булып, шуларнын барысы да бакчага йори. Аларны тәрбияләудә 1 тәрбияче, 1 повар, 1 кече тәрбияче хезмәт курсәтә. Тәрбияләү эшләре график нигезендә алып барыла. Коллектив балалар белән берлектә авылда уздырыла торган, районкулэмендэ чараларда актив катнашалар, мактау хатларына лаек булалар. Яңа ел алдыннан һәр елдагыча балалар бакчасына Бердәм Россия партиясе уенчыклар белән ярдәм итә. Берничә ел дәвамында Партия вәкилләре буләклэрне алып килеп балаларга тапшыра. Балалар һәм эти-энилэр өчен бу чара олы бәйрәмгә әйләнә. Район житәкчеләренә уземнен, эти-энилэр һәм бакча хезмәткәрләре исеменнән рәхмәтебезне житкерэбез (реорганизация с сентября)

**Мәдәният йортының** эшен 3 кеше алып бара. Эш алдан тозелгән план нигезендә халыкнын ялын файдалы, кунелле итеп оештыру максатыннан чыгып уткәрелә. Авылыбызның бай тарихы, узенә генә хас бәйрәмнәре, гөреф-гадәтләре, йолалары бар. Шуларны өйрәну, саклау, киләчәк буынга тапшыру безнен бурычыбыз булып тора һәм шунын остендә ел дәвамында эшләр алып барыла. Район буенча уздырылган смотрларда һәм башка чараларда актив катнашып, күп кенә призлы урыннарга лаек булдык. Эшләнгән эшләр, уздырылган бәйрәмнәр турында Инстаграм челтәрендә урнаштырылган онлайн форматтагы видеороликларны карап та ел дәвамында таныша бардыгыз.

Эшләгән эшләре, куйган тырышлыклары, яулаган унышлары өчен мәдәният йорты хезмәткәрләренә, конкурсларда катнашкан авылдашларга, артистларга, балалар бакчасы хезмәткәрләренә, бакчага йөруче балаларга, аларнын әти-әниләренә зур рәхмәт.

Форсаттан файдаланып, мәдәният йортына капиталь ремонт кирәк икәнлеген дә әйтеп китәсем килә. Идән-түшәм, ишек-тәрәзә, сәхнә, җылыту челтәре бары да янарту сорый.

**Медицина хезмәте күрсәтү**- Сәпәй ФАПы Сәпәй, Мачаклы Баш авылларына хезмәт курсәтә. Бу эшне Динмухаметова Зөлфия, хэм Азнакайдан килеп Хуснуллина Резеда бик төгәл итеп алып баралар, халык алар эшеннән бик кәнагәт.

Ел дәвамында барлыгы медпунктка 2205 кеше ярдәм сорап килде, шуларга 2 314 процедура хезмәте курсәтелде, өйгә барып дәвалау 1354 очырак.

Авылга айга бер участок табибы килә, халык очен бик уңайлы. 21 яшьтән алып барлык кешеләр диспансеризация утәргә тиеш. Аны үтү өчен Азнакай узәк сырхауханәсе тарафыннан барлык шартлар да булдырылган, авылга табиплар килә, кирәкле анализлар алына, ЭКГ уткәрелә, УЗИга талон бирелә.

Короновируска каршы ясалырга тиеш булган вакцина буенча планны арттырып утэдек. 60 яшьтэн олкэннэр генэ бераз тоткарлый. Бугенге кондэге вэзгытьне истэ тотып прививкаларны ясатырга чакырам. Кемнэр бер кабат ясаткан, икенчесен ясату вакытын уткэрмичэ, ревакцинациягэ бару тиеш. Сэлэмэтлегебезгэ, бер беребезгэ игтибарлы булыйк!!!

**Почта эшен** – 2020 елнын ноябрь аеннан авылдашыбыз, 5 бала анасы Шарипова Инга Степан кызы үз өстенә алды һәм бик төгәл итеп алып бара. Өлкәннәребезгә пенсия тарата, утка, газга, чупкә, суга, телефонга түләүләр җыя, телеграммалар, посылкалар, переводлар ала, шулай ук халыкка кондәлек товар сату белән дә шөгыльләнә. Газета- журналларга язылу бик авырлык белән генә барды, шулай да елда куелган планны утәргә тырышабыз. Почта булекчәсе авыл мәдәният йортына кучеп, аерым ишекле бүлмәне җайлап эшкә керештеләр. Кучкән чакта жинелчә җыештыру эшләре генә башкарылды, әмма бу бүлмәгә дә капитал ремонт кирәк, ишек-тәрәзәләре, идән-түшәме, электр челтәре бик тузган, аяныч хәлдә. Халык өчен кереп-чыгып йору урыны да унайсыз, бүлмәдә суык.

**Китапханәдә** – 2021 елных август аеннан авылдашыбыз Регина Саетмухаметова эшли башлады. .Китапханәдән файдаланучылар саны-барлыгы 345 кеше, шулардан стационар шартларда хезмәт күрсәтелгән кулланучылар – 340 кеше, шулардан эш яшендэгелэр– 127 кеше, мэктэп яшендэгелэр -145 кеше, шуларның 14 яшькә кадәрге балалар – 90 кеше, 15тән 30 яшькә кадәр – 99 кеше, 55 яшьтән өлкәнрәкләр – 61 кеше. Стационар шартлардан тыш хезмәт күрсәтелгән кулланучылар- 5 кеше (на дому).

2021 елның октябреннән һәр шимбә 11.00 сәгатьтән 12.00 сәгатькә кадәр 3 яшьтән алып 12 яшькә кадәрге балалар өчен «Акварелька» рәсем түгәрәге

үткәрелә. 10 кешедән торган балалар түгәрәккә бик теләп йөриләр. Түгәрәктә рәсем ясаудан тыш, балалар белән төрле чаралар, конкурслар, уеннар үткәрелә.

**Ветераннар советы-**

Бугенге көндә Сәпәй авылында 160 пенсионер исәптә тора. Авыл жирлегендә караучысыз калган пенсионерлар юк. Мачаклы - Башта 16 пенсионер исәпләнә. Кызганычка каршы, жирлегебездә бер генә Бөек Ватан сугышы ветераны да калмады. Сугыш ветераннарының ялгыз хатыннары ике кеше.

Ветераннар советы эшне план буенча да, планга язылмаганнарын да даими башкарып тора.

План буенча эшләнә торган эшләр барысы да өлкәннәрне бигрәк тә ялгызларны шатландырып, бергәләп матур итеп яшәү максатыннан оештырыла.

Ел дәвамында һәр пенсионерны туган көне белән котлап, хәлләрен сорашып, ярдэмлэшеп торабыз. Мәдәният йортында уздырылган һәр календарь бәйрәмдә олкэннэребезгэ игьтибарлы булып, бәйрәмнәргә чакырабыз.

Ел башы яңа ел кичәсе белән башланып китә. Яна ел бәйрәме авылның имамы, авыл җирлеге башлыгы һәм ветераннар советы тәбрикләүләре белән башлана. Гадәттә бу бәйрәмдә яше-карты бик актив катнаша. 12 нче гыйнвар көне авылның өлкән яшьтәге ветераннарын һәм инвалид балаларнын өйләренә йөреп, Кар кызы белән Кыш бабай үзләренең кечкенә генә бүләкләрен тапшыруны оештырабыз.

Районда 11 ел рәттән авыл җирлекләре арасында кышкы спартакиада уздырыла. Спорт ярышларында яшьләр белән беррәттән пенсионерларыбыз да актив катнаша, призлы урыннар алып, күнелләрен күтәреп кайталар. Агымдагы елда да бу чара 19 февральдә узачак, авылдашларны ярышларда көтеп калабыз. Ә 15 январьдән сайлап алу турлары башланды. Яшьләребез бадминтон, теннис, таяк, канат тарту ярышларында катнашып яхшы гына урыннар яуладылар. Уңышлар белән ватсапта “Якташлар” төркемендә уртаклашып торабыз. Волейбол, футбол уеннары киләсе атналарда узачак.

**Халыкка 2 магазин** хезмәт курсәтә. Ахунова Резеда хэм шәхси эшмәкәр Гараева Гөлгенә. Аларнын еллык товар әйләнеше 500 000 сумнан артып китә. Халыкны азык-төлек, көнкүреш товарлары белән тәэмин итеп торалар, Бу эшмәкәрләребез авылда уздырыла торган чаралардан да читтә калмыйлар, хәләреннән килгәнчә ярдәм итәләр. Бик зур рэхмэтлебез аларга, эшләрендә уңышлар телибез.

Авылыбыз **Мәчете-** яхшы гына эшләп килә, өлкәннәребез бик теләп йөри, һәр көн Азан тавышы авылыбызга яңгырый. Мэчетебезнен шурасы тозелде. Хәзрәтебез Хусаенов Альберт абый үз эшен җиренә җиткереп башкара.Пандемия хикмәте белән 2021 елда да мәчеттә чаралар үткәрелмәде, укулар да оешмады. Ураза, Корбан бәйрәмнәре саклык чаралары белән өйләрдә генә уздырылды.
Мэчетебез ел саен балалар бакчасына йоруче балаларга хэм момкинлеклэре чикле авылдашларга яна ел булэклэре эзерлэп, таратып чыга. Игелегегез очен Аллахнын рэхмэте булсын.

Эшләнгән эшләрне сөйләве күңелле, күрергә теләгән кешегә күренеп тә торалар. Хөрмәтле авылдашлар, әле эшлисе эшләребез дә күп. Шуна курә йорт хуҗаларына әйтеп үтәсе килә, пропискада булган һәркем өчен үзара салым түләү мәҗбүри. Сез пропискага рөхсәтегезне биргәнсез икән бу кешеләр өчен җаваплылык та сезнең өстә.

Хөрмәтле авылдашлар! Агымдагы елда да Рәсәй күләмендә чүпләрне җыеп алу буенча Бердәм оператор хезмәте күрсәтелә. Бу очракта Закон нигезендә йорт хуҗалары, пропискада булган кеше саны белән һәр йорт чүп җыю өчен түләргә тиеш. ***Түләү суммасы да сизелеп артты, түләү тәртипләре дә үзгәрде.***

Чүп жыю машинасы Сәпәйгә һәр сишәмбе, Мачаклы- Башка җомга көнне килә, Капчыкларга тутырылган чүплэрне җыеп алып китә. Күләмле чүпләрне җыелып трактор арбасы белән чыгарырга мөминлек булыр дип сөйләшсәк тә, кайбер хөрмәтле авылдашлар жиңел машинага арба тагып бәрәңге сабагын, бакча чүпләрен урман буйларына, карьерга, чистартып эттереп куйган бикле чүплекнең койма буена, чокырларга илтеп бушаттылар. Бер дә күңелле хәл түгел, Хөрмәтле авылдашлар! Чистарткан җирдә түгел чүпләмәгән җирдә чиста була диләр.Барыбыз бер булып чисталык өчен көрәшмәсәк, чүптән котыла алмыйбыз.!!!

Хөрмәтле авылдашлар! Авылыбызда тагын тәрбиягә авыр бирелүче, авыр социаль хәлле гаиләләр барлыкка килде. Бу спиртлы эчемлекләр белән мавыгучылар. Авыл җирлегендә оештырылган иҗтимагый совет, район оешмалары белән берлектә шул гаиләләр белән эш алып бара. Утка, газга түләү, янгын хәбәрчеләре алып кайтып урнаштыру- барысы да җирлек өстендә. Сонгы елларда социаль яклау оешмасы тарафыннан 5 йортка янгын хәбәрчеләре куелган булса, авыл җирлеге тарафыннан тагын 5 йортка урнаштырылды. 2 йортка элек куелганнарынын аккумуляторлары алыштырылды. Хөрмәтле авылдашлар! Бер-беребезгэ, күршеләргә, ялгыз яшәүче әби-бабайларга итагәтъле, игътибарлы булсак иде.

Җирлектэ озак еллар **"ирекле янгын дружинасы"** эшли. Язгы-җәйге чорда янгын куркынычсызлыгын саклауда, янгын булган очыракта сүндерүдә шул иптәшләр аеруча актив катнаша. Гомумән, битараф булмаган Сәпәй Мачаклы халкына рәхмәт сүзләре әйтәсе килә. Мачаклыдан Исламова Флера, Ханова Аллюра апа, Сәпәйдән депутатыбыз Гарайшин Наил, бертуганнар Закиров Алмаз һәм Айдар Айратовичлар, Гарипов Артур, Шарипов Раил, уллары Рамиль, Рафаэл белән, Нуркаев Рузалин абый һәм башка бик күпләр...

Бу урында җирлектәге тагын бер оешма "**ирекле халык дружинасы**" турында да әйтеп китәсе килә. Бу оешма әгъзалары булып авылдагы оешма хезмәткәрләре эшли. Җомга, шимбә көннәрендә, язгы-көзге эшләр вакытларында ындыр табагы, оешма тирә-яклары, мәчет территориясен тикшереп, карап тору алар җилкәсендә. Хезмәтегез очен зур рәхмәт кызлар!!!

Урамда йөргән хужасыз этләргә халык зарлана. Бүгенге көндә Татарстан Республикасы министрлар кабинеты карары нигезендә хуҗасыз этләрне торак

йортлар булган жирдә ату тыела. Этләрне жыеп алу, аларны тиешле шартлары булган урыннарга илтеп урнаштыру белән махсус рөхсәте булган оешмалар гына шөгыльләнә ала. 2021 елда Азнакай МППБ иО хезмәткәрләре белән халыкнын кош-кортларына  каза салган күп кенә этләрне җыеп алдык. Урамда йөрүче этләрнен күбесе хуҗалы, муенында муенчаклы. Бу елны безнен өчен бик кирәк булган приют та вакытлыча эшчәнлеген туктатып торды, шул вакытта куп зыян китерделәр. Һәркем үз этен бәйләп куйса, хуҗасызларны җыеп ашатмаса, этләр бераз булса да кимерләр иде.

Чыгышымны тэмамлап авыл халкына эйтэсем килэ:

1. 2020 елларның транспорт, йорт-җир налогларын җыю бик авырлык белән барды. Бугенге көндә агымдагы елның түләнмәгән налоглар исемлеге килде. Шул ук бер кешеләр. Әгәр, суд карары белән түләтә башласалар, түләнмәгән налог, өстәмә пеня һәм суд расходлары өстәлә. Карар суд приставларына тапшырыла, вакытында түләмәгәч, аларның расходлары да өстәлә.  Күпкә артык түләгәнче, вакытында эшне бетереп кую кирәк. Соңиаль яклау идарәсеннән, савым сыерлар, савым кәҗәләр өчен алынила торган субсидияләр дә түләнмәячәк икәнен алда әйтеп аңлатып киттем!!!
2. Авылда  рәсмиләштерелмәгән  җирләр, йортлар, яңа салынган йортлар бар. Һәркемнең милеге тиешле документлар ясалып, теркәү оешмасында регистрация үткән булырга тиеш. Бу эшләр хөкумәт контролендә. Беренче катка 500 сум штраф булса, кабат салганда суд карары белән 30 000 карала. Регистрация үткәреп, документларны авыл советына китерү мәҗбүри!

ШУНЫН БЕЛЭН ЧЫГЫШЫМ ТЭМАМ,

Игътибарыгыз өчен рәхмәт. Һәркайсыгызга исәнлек-саулык, бәрәкатле имин тормыш телим.